| | | |
|---|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**<br><br>**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**<br><br>**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«23» ноября 2021 с. Тюлячи № 292

«Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы» муниципаль берәмлеге милкендәге, сатулары сәүдәләр үткәрмичә генә башкарыла торган, җир кишәрлекләренең бәяләрен билгеләү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Җир кодексының 39.4 статьясындагы 2 пунктының 2 пунктчасы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 елның 11 июнендәге 432 номерлы «Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләренең яисә дәүләт милке чикләнмәгән, сату сәүдәләр үткәрмичә гамәлгә ашырыла торган җир кишәрлекләренең бәясен билгеләү тәртибен раслау турында» карары нигезендә, «Теләче муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре Палатасы» муниципаль учреждениесенең 2021 елның 17 ноябрендәге 205 номерлы хатын карап, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы» муниципаль берәмлеге милкендәге, сатулары сәүдәләр үткәрмичә генә башкарыла торган, җир кишәрлекләренең бәяләрен билгеләүнең кушымта итеп бирелгән Тәртибен билгеләргә.

2. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
«23» 11 2021 № 292
карарына кушымта

«Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы» муниципаль берәмлеге милкендәге, сатулары сәүдәләр үткәрмичә генә башкарыла торган, җир кишәрлекләренең бәяләрен билгеләү тәртибе

1. Әлеге Тәртип «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы» муниципаль берәмлеге милкендә булган җир кишәрлекләре бәясен билгеләү кагыйдәләрен билгели, аларны сату, Россия Федерациясе Җир кодексының 39.3 статьясындагы 2 пунктының 1-5, 7, 9 һәм 10 пунктчалары нигезендә, сәүдәләр үткәрмичә гамәлгә ашырыла.

2. Базар бәясенә тигез, әмма кадастр бәясеннән артмаган бәядән сату башкарыла:

1) территорияне комплекслы үзләштерү өчен арендага бирелгән җир кишәрлегеннән төзелгән җир кишәрлекләре, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә территорияне комплекслы үзләштерү турында шартнамә төзелгән затка;

2) гражданнар тарафыннан төзелгән коммерциягә карамаган оешма тарафыннан бирелгән җир кишәрлегеннән төзелгән җир кишәрлекләреннән индивидуаль торак төзелеше максатларында территорияне комплекслы үзләштерү өчен (гомуми файдаланудагы мөлкәткә кертелгән җир кишәрлекләреннән тыш), әлеге коммерциягә карамаган оешма әгъзаларына яисә, бу коммерциягә карамаган оешма әгъзаларының гомуми җыелышы карары белән каралган булса;

3) бакчачылык яки яшелчәчелек коммерцияле булмаган ширкәтенә бирелгән җир кишәрлегеннән төзелгән җир кишәрлекләре, гомуми кулланылыштагы җир кишәрлекләреннән тыш, мондый ширкәт әгъзаларына;

4) Россия Федерациясе Җир кодексының 39.9 статьясындагы 2 пунктында күрсәтелгән затлардан тыш, юридик затларның даими (сроксыз) файдаланылышында булган җир кишәрлекләре (әлеге җир кишәрлекләрендә биналар, корылмалар булмаган очракта);

5) авыл хуҗалыгы җитештерүен алып бару өчен билгеләнгән һәм гражданга яисә юридик затка арендага тапшырылган җир кишәрлекләре әлеге граждан яисә әлеге юридик зат белән аренда шартнамәсе төзелгән вакыттан соң өч ел узгач йә җир кишәрлеген арендалау шартнамәсе буенча хокуклар һәм бурычларын шушы гражданга яисә әлеге юридик затка тапшырган очракта, вәкаләтле органның дәүләт җир күзәтчелеге кысаларында ачыкланган һәм Россия Федерациясе законнарының юкка чыгарылмаган бозылышлары турында мәгълүмат булмаган очракта, әлеге граждан яисә юридик зат мондый җир кишәрлеген сату-алу шартнамәсен төзү турында гариза сәүдәләр үткәрмичә генә биргән очракта, җир кишәрлеген арендалау шартнамәсе срогы тәмамланганчы биргән очракта;

6)Россия Федерациясе Җир кодексының 39.18 статьясы нигезендә крестьян (фермер) хуҗалыгы эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен гражданнарга индивидуаль торак төзелеше, торак пункт чикләрендә шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару,

бакчачылык, дача хуҗалыгы өчен гражданнар яисә крестьян (фермер) хуҗалыкларына җир кишәрлекләре.

3. Җир кишәрлегенең кадастр бәясеннән унбиш процентка тигез бәядән гражданнар тарафыннан төзелгән коммерциягә карамаган оешма биргән җир кишәрлеген индивидуаль торак төзелеше максатларында территорияне комплекслы үзләштерү өчен һәм гомуми файдаланудагы мөлкәткә караган әлеге коммерциягә карамаган оешмага бирү нәтиҗәсендә барлыкка килгән җир кишәрлекләрен сату гамәлгә ашырыла.